**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА АЗНАКАЕВО АЗНАКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Ленина, д.14, г. Азнакаево, 423330

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЗНАКАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Ленин ур.-14 нче йорт, Азнакай ш., 423330

Тел./факс(885592)7-15-50, 7-00-37; E-mail:aznakay@tatar.ru кат adm-aznakay@mail.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«25» май 2020 ел № 20

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Азнакай шәһәренең «Яңа Юл»
микрорайонында урамнарга
исем бирү турында

2003 елның 06 октыбрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, Татарстан Республикасының 2016 елның 29 сентябрендәге 74-ЗРТ номерлы «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» законы нигезендә, Татартан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Башкарма комитетының 2009 елның 22 октябрендәге 150-36 номерлы карары белән расланган Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең Генераль планы нигезендә

1. Азнакай шәһәренең «Яңа Юл» микрорайонында яңа барлыкка килгән урамнарга түбәндәге исемнәрне бирергә:

1 нче кушымтада бирелгән карта-схема нигезендә , «100 лет ТАССР улица» - «ТАССРга 100 ел урамы», «А.Исхакова улица» - «Ә.Исхаков урамы», «Р.Шакурова улица» - «Р.Шәкүров урамы», «Н.Ихсановой улица» - «Н.Ихсанова урамы», «А.Шакирова улица» - «Ә.Шәкиров урамы», «Тихая улица» - «Тихая урамы».

2. Әлеге карарны тормышка ашыру буенча чаралар күрергә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.http://pravo.tatarstan.ru

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче М. И. Солтанов